ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.02.2021 № 130

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 16.01.2019 елдагы 17 номерлы карарына үзгәреш кертү турында

РФ Юстиция министрлыгының 2017 елның 23 июнендәге 2754 номерлы боерыгы белән 2021 елның 17 гыйнварыннан норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрүгә вәкаләтле бәйсез эксперт сыйфатында аккредитацияләнгән Р. М. Гибатдиновның бәяләмәсе нигезендә һәм кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш буенча комиссия төзү турында» 2019 елның 16 гыйнварындагы 17 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

3.5 пунктны 2 нче кушымтада түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «3.5. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия утырышында тавышлар тигез булганда, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч санала».

3.6 пунктны 2 нче кушымтада түбәндәге редакциядә бәян итәргә « " 3.6. Һәр утырыш нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә, анда Комиссия каравына кертелгән мәсьәләләр, шулай ук алар буенча кабул ителгән карарлар теркәлә. Беркетмәгә комиссия рәисе һәм секретаре кул куя. Беркетмәгә утырышта Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасы тарафыннан әйтелгән аерым фикер кертелә. Комиссия утырышы беркетмәсен рәсмиләштерү вакыты-өч эш көне эчендә».

Җитәкче Р.Р. Хәмзин

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
19.02.2021 ел, № 130 карарына 1 нче кушымта

## Нурлат муниципаль районы территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш буенча Комиссия составы

| | |
|---|---|
| Хәмзин Р.Р. | - Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Усманов С.Ф. | - Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Йосыпова Ю.И. | - "Нурлат муниципаль районының архитектура планлаштыру һәм шәһәр төзелеше идарәсе" МУП директоры, комиссия секретаре (килештерү буенча); |

<u>Комиссия әгъзалары:</u>

| | |
|---|---|
| Нәфыйгина Л.М. | - Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары; |
| Логинова Л.В. | - Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының төзекләндерү һәм шәһәр хуҗалыгы бүлеге баш белгече; |
| Гәрәев М.М. | - Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы; |
| Сәйфетдинова З.Р. | - Нурлат муниципаль районы "Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы" МКУ рәисе (килешү буенча); |
| Титарева О.А. | - Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге начальнигы. |